Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

3 ноябрь, 2020 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең Аркатау торак пункты гражданнарының 2020 елның 3 ноябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 21 (егерме бер).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 14 (ундүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гөмуми сан 14 (ундүрт).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2021 елда Аркатау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов